БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

# КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

№ 93 (5893) | ДүШӘМБЕ. 22 АПРЕЛЬ, 1940 ЕЛ. | АЕРЫМ НОМЕРЫ 10 ТИЕН.

**БӨТЕН ДӨНЬЯ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕНЕҢ БӨЕК ЮЛБАШЧЫСЫ ВЛАДИМИР ИЛЬИЧ ЛЕНИННЕҢ ТУУЫНА БҮГЕН 70 ЕЛ ТУЛДЫ**

## Лениннең бөек идеяләре тормышка ашырылды

Социалистик революциянең даһи полководецы, бөтен дөнья хезмәт ияләренең сөекле юлбашчысы, бөек остазы, атасы һәм иң якын дусты Владимир Ильич Лениннең тууына бүген 70 ел тулды.

Владимир Ильич Ленин үзенең бөтен гомерен революция өчен, бөтен дөнья хезмәт ияләренең азатлыгы, бәхте, шатлыгы өчен көрәшкә багышлады һәм тормышының актык сулышына кадәр шул көрәшне дәвам иттерде.

Бөтен дөнья күләмендәге эшчеләр хәрәкәтенең иң гүзәл сәхифәләре, Россия эшчеләренең һәм крестьяннәренең капиталистларга, алпавытларга, патша самодержавиесенә каршы героик көрәшләре, җир шарының алтыдан бер өлешендә Бөек Октябрь Социалистик Революциясенең җиңүе — болар барсы да турыдан-туры Владимир Ильич Лениннең исме белән бәйләнгәннәр.

Данлыклы большевиклар партиясен, социалистик революциянең бөтен дөнья күләмендәге сугышчан штабы булган Коммунистик Интернационалны төзүче һәм аларның юлбашчысы, кешелек дөньясы тарихында беренче тапкыр төзелгән социалистик дәүләтнең җитәкчесе Владимир Ильич Ленин булды.

Карл Маркс, Фридрих Энгельс, Владимир Ильич Ленин, Иосиф Виссарионович Сталин — болар җир шарының барлык почмакларында сәгат саен, минут саен миллионнарча кешеләр тарафыннан телгә алына торган исемнәр. Эксплоататор-паразит сыйныфлар өчен бу исемнәр дәһшәтле курку тудыралар, аларның ачуларын кабарталар, һәм бу бик табигый нәрсә. Прогрессив кешелек дөньясы исә бу бөек исемнәрне зур ихтирам һәм горурлык белән телгә ала, җир шарындагы барлык хезмәт ияләренең йөрәгендә бу исемнәр көрәш һәм җиңү байрагы булып сакланалар.

Кешелек дөньясының бөек галимнәре, эшчеләр сыйнфының һәм хезмәт ияләренең даһи юлбашчылары, фәнни социализмның аталары—Карл Маркс һәм Фридрих Энгельс капиталистик җәмгыятне җентекләп тикшерү, аңарга тирән анализ бирү нәтиҗәсендә капитализмның кискен каршылыкларын ачып салдылар һәм аның һәлакәтенең котылгысыз икәнен күрсәттеләр. Ләкин, капитализмның бу һәлакәте үзеннән-үзе булмаячагын, аны һәлак итү—юкка чыгару тик пролетар революция аша гына булачагын, капитализмны тар-мар итеп, аның урнына яңа—социалистик җәмгыят төзүдә җитәкчелек итү роле эшчеләр сыйнфы кулында булырга тиешлекне күрсәттеләр.

Маркс, Энгельс яшәгән чор—капитализмның чәчәк ату чоры, монополистик капитализмга кадәр булган чоры иде. XIX нчы йөзнең ахрында, XX нче йөзнең башында капитализм үзенең үсешендә иң югары һәм иң соңгы стадиягә керде, ул инде империалистик капитализм булып әверелде. Маркcның революцион таглиматына таянып, Ленин капитализм үсешендәге бу стадияне тирәнтен тикшерде һәм аның барлык каршылыкларын ачып салды. Империализмнын череп һәм үлеп баручы капитализм икәнлеген, социалистик революциянең алды булуын бай материаллар белән исбат итте.

Маркс, Энгельс капитализмның империалистик чорына кадәр булган вакытта яшәгәнлектән, бу яңа фазага көчү уңае белән килеп чыккан яңа шартлар турында тик сизенә генә алдылар, фактларга тулы анализ бирә алмадылар. Империализм һәм пролетар революция эпохасында яшәгән Ленин генә бу чорга карата тулы нәтиҗә ясады. Империализм эпохасында капитализмның экономик һәм политик яктан тигезсез үсүе котылгысыз закон.

Шуның аркасында капитализм фронты йомшак җиреннән өзелергә мөмкин. Шушы закон нигезендә Ленин, социализмның башта аз гына һәм хәтта аерым алынган бер илдә генә дә җиңүе мөмкинлекне һәм социализмның барлык илләрдә дә бер үк вакытта җиңүе мөмкин түгеллекне теоретик яктан нигезләде.

Лениннең аерым алынган бер илдә социализмның җиңүе мөмкин икәнлек турындагы теориясе бөтен дөнья пролетарларының капитализмга каршы көрәшендә якты маяк булып хезмәт итә, бу теориянең әһәмияте шул кадәр зур ки, аңа бәя биреп бетерү мөмкин түгел.

Лениннең бу теориясе коммунизм өчен көрәштә Ленин—Сталин партиясе өчен гаять көчле идея коралы булып хезмәт итә. Бу бөек теория безнең илебез шартларында материаль көч булып әверелде. Советлар Союзында барлык эксплоататор сыйныфлар тәмам бетерелделәр, кешенең кешене эксплоатацияләвен тудыра торган сәбәпләр тулысынча юк ителделәр. Безнең илебездә коммунизмның беренче фазасы—социализм нигездә тормышка ашырылды.

Ленинчел-Сталинчыл теориягә, бер илдә социализмның җиңүе теориясенә троцкичылар, бухаринчылар, буржуаз милләтчеләр һәм халыкның башка дошманнары күп еллар буена һөҗүм итеп килделәр. Халыкның бу кабахәт дошманнары социализм төзү эшен җимерергә, капитализмны яңадан урнаштырырга маташтылар. Ләкин, совет халкы Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә үзенең дошманнарын төбе-тамыры белән тар-мар итте.

Лениннең бер илдә социализмның җиңүе турындагы теориясен һәр төрле бозулардан саклап калучы, аны тагын да баетучы, үстерүче, бөек Сталин булды.

Илебезнең гаять зур уңышларга, тиңдәше булмаган җиңүләргә ирешүе өчен, бәхетле, культуралы тормышыбыз өчен, барыннан да элек, данлыклы большевиклар партиясенә—аның даһи җитәкчеләренә—бөек Ленингә һәм бөек Сталинга бурычлыбыз.

Бөек Лениннең гүзәл эше үсә, киңәя, көннән-көн яңа җиңүләр китерә. Без үзебезнең алдагы җиңүләребезгә, коммунизмның тәмам җиңүенә нык ышанабыз. Чөнки безгә данлыклы партиябез—Ленин—Сталин партиясе, марксизм-ленинизм теориясе белән коралланган бөек партия җитәкчелек итә. Чөнки безнең эшебезгә, даһи Лениннең бөек көрәштәше—иптәш Сталин җитәкчелек итә.

Яшәсен Маркс — Энгельс — Ленин—Сталинның җиңелмәслек бөек байрагы!

Яшәсен ленинизм!

### Ленин яшәгән һәм эшләгән урында

„1894 нче елны бу йортта, 13 нче квартирада, большевиклар партиясенә нигез салучы, бөтен дөнья коммунизмының юлбашчысы В. И. Ленин торды". Ленинградта, Ильич тыкырыгында (элекке Большой Казачийда) 7/4 нче номерлы, өч катлы, борынгы бер йортның фасадында куелган истәлек тактага әнә шул сүзләр язылган.

Ишек алдындагы баскычтан өченче катка менелә. Менә 13 нче квартира. Аның тәбәнәк түшәмле, кечрәк кенә өч бүлмәсе бар. Коридор башындагы соңгы бүлмәдә яшь чагында Владимир Ильич торган. Бу—13 метрлы бүлмә булып, аның кара-каршы ясалган ике кечкенә тәрәзәсе бар. Бер тәрәзә янында буялмаган чиста өстәл, аның өстендә керосин лампасы. Берничә гади венский урындык, тупас йон одеял җәелгән тимер кровать, кустарча эшләнгән диван, комод, почмакта, пич янында умывальник, стенада кием элгеч.

Бу гади генә бүлмәдә кешелек дөньясының бөек даһие 1894 нче елның 24 (12) нче февраленнән 1895 нче елның 7 нче маена (25 нче апреленә) кадәр торган. Монда Владимир Ильич үзенең „Нәрсә ул „халык дуслары" һәм алар социал-демократларга каршы ничек сугышалар?" дигән атаклы китабын һәм „Народниклыкның экономик эчтәлеге һәм Струве әфәнде китабында аның тәнкыйть ителүе" дигән әсәрен язган.

Монда һәр елны эшчеләр, хезмәткәрләр, укучылар, кызыл армеецләр һәм йорт хозяйкалары киләләр. Алар Ильич бүлмәсе белән һәм шул замандагы тарихи документлар белән танышалар. Йорт-Музей ачылганнан бирле ел ярым эчендә 12 меңнән артык кеше булды. (ТАСС).

## ВЛАДИМИР ИЛЬИЧ ЛЕНИН

*(КЫСКАЧА БИОГРАФИЯ)*



Владимир Ильич Ленин 1870 нче елның 22 нче апрелендә (иске стиль белән 10 нчы апрельдә), хәзер Ульяновск дип атала торган Сембер шәһәрендә туган.

Лениннең атасы Илья Николаевич Ульянов ул чагында Сембер губернасындагы халык мәктәпләренең инспекторы булган, ә аңа кадәр күп кенә еллар буена Нижный Новгородта һәм Пензада физика һәм математика укытучысы булып эшләгән.

1879 нчы елны, 9 яшендә чагында Ленин Сембер гимназиясенә кергән. Ул чагында аның агасы Александр да шунда укый торган булган.

Александр Ульянов гимназияне тәмам иткәннән соң Петербург университетына укырга киткән. Анда ул народоволецлар оешмасына кергән һәм патша Александр III нчене үтерүне хәзерләүдә катнашкан. 1887 нче елның 13 нче мартында (иске стиль белән 1 нче мартта) Александр Ульянов үзенең иптәшләре белән берлектә кулга алынган, ә 1887 нче елның 20 нче маенда (иске стиль белән 8 ндә) үтерелгән.

Агасының җәзаланып үтерелүен белгәч Ленин: „Юк, без бу юл белән бармабыз, без бүтән юл белән барырбыз" дигән. Бу юлны Ленин Карл Маркcның һәм аның көрәштәше Фридрих Энгельснең революцион тәглиматыннан тапты. Маркс һәм Энгельс әсәрләре Лениннең өстәл китаплары булып әвеределәр. Ленин марксист булып әверелде.

1887 нче елны бик яхшы уңышлары өчен алтын медаль алып Сембер гимназиясен тәмам иткәннән соң Ленин Казан университетына керә.

17 яшлек Владимир Ульянов Казан университетында укый башлавының беренче елында ук беренче тапкыр сугышчан чыныгу ала: 1887 нче елның 17 нче декабрендә ул студентларның революцион хәрәкәтендә катнашкан өчен, студентлар җыелышын оештыручыларның һәм анда актив катнашучыларның берсе дип каралып кулга алына һәм Казаннан 40 чакырым еракльктагы Кокушкино авылына сөрелә. Анда ул полиция күзәтүе астында яши. Ленин Кокушкинода күп кенә укып, үзенең белемен арттыра.

Тик 1888 нче елның көзендә генә Ленингә Казанга кайтырга рөхсәт бирәләр. Бу вакытта аның туганнары Казанга күчеп килгән була. Ләкин аңа университетка кайтырга рөхсәт итмиләр.

Казанда Ленин Федосеев тарафыннан оештырылган марксистик түгәрәкнең эшендә актив катнаша. Нак менә шул вакытта Ленин Маркcның „Капитал"ын тирәнтен өйрәнә башлый.

1889 нчы елның азагында Ленин, семьясе белән берлектә, Самарага күчеп китә. Анда ул марксистик түгәрәк оештыра. Ул елларда ук инде Ленин үзенең марксизмны белүе белән һәр кемне гаҗәпләндерә. Шулай ук ул Россиядәге революцион хәрәкәт тарихын да өйрәнә һәм крестьян мәсьәләсен аеруча игтибар биреп өйрәнә. Крестьян мәсьәләсен белү народникларга каршы көрәштә Ленингә ярдәм итте.

Университетны тәмам итәргә карар биреп, Ленин экзаменга хәзерләнә. 1891 нче елны Ленин Петербург университетының юридик факультеты буенча экзаменнан үтә һәм 1 нче дәрәҗә диплом ала.

1893 нче елның сентябрендә Ленин яңадан Петербургка килә һәм тиз арада, марксистлар сыйфатында революцион эш алып баручы иптәшләрнең барсы белән яңадан таныша. Ленин тирәсенә революцион эштә иң коюю һәм иң эшлекле төстә катнашучылар җыела башлыйлар. Лениннең беренче чыгышлары ук Петербургтагы марксистик түгәрәкләрдә катнашучыларга гаять көчле тәэсир ясыйлар. Эшчеләр сыйнфының җиңәчәгенә тирәнтен һәм нык ышану, күрнекле оештыручылык таланты Ленинне Петербург марксистларының танылган җитәкчесе иттеләр.

Ленин Петербугка килгән вакыттан алып ул беренче партия оешмасын—Петербург „Эшчеләр сыйнфын азат итү өчен көрәш союзы"н төзү эшен башлый. Петербург „Көрәш союзы" эшчеләр хәрәкәтенә таянучы марксистик революцион партиянең башлангычы булды. Союз эшчеләрне политик яктан тәрбияләде, экономик таләпләр өчен көрәшне царизмга каршы политик көрәш белән бергә бәйләде. Петербург „Эшчеләр сыйнфын азат итү өчен көрәш союзы", Ленин җитәкчелегендә булган хәлдә, социализмны эшчеләр хәрәкәте белән бергә кушуны уңышлы рәвештә тормышка ашыра башлады.

Россиядә марксистик социал-демократ эшчеләр партиясе, беренче чиратта, марксизмның иң явыз дошманы булган народниклыкка каршы көрәштә туды һәм үсте.

Петербургта Ленин 1894 нче елны „Нәрсә ул „халык дуслары" һәм алар социал-демократларга каршы ничек сугышалар?" дигән гүзәл китабын язды. Бу китабында Ленин народникларның, чынлыкта халыкка каршы чыккан ялган „халык дуслары" ның чын йөзен, аларның карашларының зарарлы һәм ялгыш икәнлеген ахрынача фаш итте. Ленин, капиталистларның һәм алпавытларның изүен юк итәргә теләүче, царизмны юк итәргә теләүче чын халык дуслары народниклар түгел, бәлки марксистлар икәнлекне күрсәтте.

Ленин үзенең „Нәрсә ул халык дуслары" дигән китабында эшчеләр сыйнфының җәмгыятнең алдынгы көче булучылык ролен билгеләде һәм, беренче буларак, эшчеләр сыйнфы җитәкчелегендә эшчеләрнең һәм крестьяннәрнең революцион союзын төзү турындагы фикерне бирде. Бу союз царизмны, алпавытларны һәм буржуазияне бәреп төшерүнең төп коралы булырга тиеш булды. Ленин үзенең китабында рус марксистларының төп бурычларын һәм, барыннан да элек, таркау түгәрәкләрдән бердәм социалистик эшчеләр партиясе оештыруны билгеләде.

Россиядә марксизм киң күләмдә җәелә башлады. Ул студентларны, интеллигенциянең бер өлешен үзенә тарта башлады. Марксизмга „легаль марксистлар" дип аталган попутчиклар килеп сырыша башладылар.

Буржуаз интеллигентлар марксистик киемнәр киенә башладылар. Алар патша хөкүмәте тарафыннан рөхсәт ителгән легаль газеталарда һәм журналларда үзләренең мәкаләләрен бастыра башладылар. Алар эшчеләр хәрәкәтен буржуазия интересларына буйсындырырга маташтылар.

Маркс тәглиматыннан алар иң әһәмиятлесен—пролетар революция турындагы, пролетариат диктатурасы турындагы таглиматны алып ташладылар. Иң күрнекле „легаль марксист" Петр Струве буржуазияне мактады һәм революцион көрәш урнына „культурасызлыгыбызны икрар итәргә һәм капитализмнан өйрәнергә барырга" чакырды. П. Струвега каршы Ленин 1894 нче елны „Народниклыкның экономик эчтәлеге һәм аның Струве әфәнденең китабында тәнкыйть ителүе (буржуаз әдәбиятта марксизмның чагылуы)" дигән китабын язды. Ленин „легаль марксистлар" ны пролетариатка буржуаз йогынты үткәрүчеләр дип атады.

Ленин эшчеләрнең берничә революцион түгәрәкләрен оештырды һәм эшчеләр белән үзе шөгылләнде, аларның укытучысы булды. Ләкин шуның белән бергә Ленин үзе дә эшчеләрдән өйрәнде: аларның ничек яшәүләрен, ничек эшләүләрен, фабрикаларда, заводларда аларны барыннан да күбрәк нәрсә борчыганлыкны, хәзерге вакытта аларның барыннан да күбрәк нәрсә турында борчылуларын алардан тулы итеп сорашты. Шушы сөйләшүләр һәм эшчеләр мәсьәләсен өйрәнү нигезендә Ленин хуҗаларга каршы ничек көрәшергә кирәклекне эшчеләргә аңлаткан листовкалар язды.

1895 нче елның апрель ахрында Ленин чит илгә китте. Швейцариядә ул „Хезмәтне азат итү" группасы членнары белән—Плеханов, Аксельрод һәм башкалар белән танышты. Шунда ул чит илләрдәге социалистик хәрәкәтнең шул замандагы күрнекле эшлеклеләре белән—Поль Лафарг һәм Германия социал-демократларының күрнекле җитәкчесе Вильһельм Либкнехт белән танышты.

Чит илдән кайтканнан соң Ленин күп кенә шәһәрләрне—Вильно, Москва, Орехово-Зуево һәм башка шәһәрләрне йөреп чыкты. Ул социал-демократ эшчеләр белән танышты һәм аерым оешмаларны бердәм эшчеләр партиясенә берләштерү өстендә эшли башлады. 1895 нче елның декабрендә Ленин „Көрәш союзы" буенча үзенең башка иптәшләре белән берлектә кулга алынды.

Ләкин төрмәдә дә Ленин эшчеләр хәрәкәтенә җитәкчелек итү буенча үзенең эшен ташламады. Ул социал-демократик партиянең программа проектын төзи (проект медицина китабының юллары арасына сөт белән язылган була), „Стачкалар турында" брошюра һәм листовка яза. Ленингә төрмәгә китаплар, журналлар китерәләр, ул иртәдән төнгә кадәр утырып „Россиядә капитализмның үсеше" дигән зур китабын хәзерли. 1897 нче елның февралендә Ленинне 3 елга Көнчыгыш Себергә, Минусинск өязенә сөрәләр. Анда, Шушенское авылында Ленин 3 ел тора.

(ДӘВАМЫ 2 нче БИТТӘ).

# ВЛАДИМИР ИЛЬИЧ ЛЕНИН

*(ДӘВАМЫ)*

Бу вакытта, Лениннең булачак көрәштәше һәм партиянең булачак юлбашчысы, Лениннән ун яш чамасына яшрәк булган иптәш Сталин Закавказье эшчеләре арасында үзенең эшен башлый.

1898 нче елның маенда Шушенское авылына үзенең анасы белән берлектә Надежда Константиновна Крупская килә. Ул да шулай ук „Көрәш союзы“ эше буенча кулга алынган һәм Себергә сөрелгән була.

Ленин төрмәдә яза башлаган китабын,—„Россиядә капитализмның үсеше“ турындагы китабын дәвам иттерү эшенә сөргендә яңадан тотына. Ленин бу китабы белән народникларны идея ягыннан тар-мар итүне тәгәлләде, эшчеләр сыйнфының көрәш һәм җиңү юлын алдан күрсәтте һәм революцион социал-демократиянең бурычларын билгеләде. Шунда ук, Себердә, Ленин „Яңа фабричный закон“ дигән массовый китабын да тәмам итте. Бу китап чит илдә „Хезмәтне азат итү группасы“ тарафыннан бастырылды. Шунда ук Ленин „Рус социал-демократларының бурычлары“ дигән атаклы брошюрасын да язды. Бу китап ул заманда Россиядәге марксистларның эшенә ныклы юнәлеш бирде. Шулай ук сөргендә Ленин партиябез программасының проектын да язды.

1899 нчы елны Россиядә „экономистлар“ группасының мөраҗәгате килеп чыкты. Бу, марксизмнан тәмам баш тарту, эшчеләр сыйнфының үзенә аерым революцион партиясен төзүдән баш тарту, эшчеләр сыйнфының үзенә аерым политик таләпләреннән баш тарту дигән сүз иде. Сөргендә үзенең дуслары аркылы „экономистлар“ның оппортунистик мөраҗәгатен алганнан соң Ленин сөргендәге марксистларны җыйды һәм алар белән бергәләп кискен фаш итү протесты төзеде. Бу, „17 социал-демократның протесты“ дигән исем астында маглүм. Марксистик фикерне һәм марксистик партияне үстерү эшендә бу протестның гаять зур әһәмияте булды.

„Рус социал-демократиясендә артка таба юнәлеш“ дигән исем астында шуннан соң язган мәкаләсендә Ленин „экономистлар“ның халыкара оппортунизмга Россиядәге иярүчеләр, ягни буржуазия ярдәмчеләре икәнлеген күрсәтте.

Ленин сөргендә вакытта аның „Россиядә капитализмның үсеше“ дигән китабы легаль рәвештә басылып чыкты. Лениннең бу фәнни әсәре народниликны идея ягыннан тар-мар итүне тәгәлләде.

1900 нче елның 10 нчы февралендә Владимир Ильичнең сөрген срогы тәмам булды, ә 11 нче февральдә инде ул Шушенскоедан китте. Уфада, Москвада, Петербургта булганнан соң Ленин Псковка китте. Анда ул марксистлар белән очрашты һәм алар белән бергәләп үзендә сөргендә вакытта ук туган планны—революцион „Искра“ газетасын чыгару планын тикшерде. Бу вакытта Ленин уннарча кешеләр белән киңәшмәләр ясый һәм хәзерлек-оештыру эше алып бара. Ленин, марксистик эшчеләр газетасы төзүнең бөтен революцион Россия өчен чиктән тыш әһәмиятле, чөнки ул түгәрәкләрнең һәм группаларның революцион эшен берләштерергә ярдәм итәчәк дип санады. Мондый газетаны чит илләрдә чыгару яхшырак, ә аннан яшрен рәвештә Россиягә китерү һәм тарату яхшы иде.

Шуннан соң Ленин үзенең гомуми рус газетасы төзү идеясен тормышка ашыру өчен чит илгә китте.

Ленин чит илдә үзенең эшен „Искра“ газетасын оештырудан, бастырудан һәм таратудан башлады. Ленинче „Искра“дан бик тизлек белән бөек революция ялгынының ялкыны кабынды.

Иң кыска вакыт эчендә Ленин исме бердәм пролетар партия төзү өчен көрәш байрагы булып әверелде. „Искра“ның чыгуы таркау группалардан һәм түгәрәкләрдән эшчеләрнең бердәм партиясен чын-чыннан төзү чорының башлануы булды.

Ленин, эшчеләр сыйнфының сугышчан партиясе, революцион марксистик партия ничек төзелергә тиешлек турында үзенең карашларын „Нәрсә эшләргә?“ дигән гүзәл китабында ачык чагылдырды.

„Нәрсә эшләргә?“ дигән әсәрнең тарихи әһәмияте шунда ки, Ленин үзенең бу атаклы китабында:

1) Марксистик фикер тарихында беренче булып оппортунизмның идея чыганакларын тамрынача ачып күрсәтте, алар, барыннан да элек, эшчеләр хәрәкәтенең стихиялелеге алдында тез чүгүдән һәм эшчеләр хәрәкәтендә социалистик аңның ролен кечерәйтүдән гыйбарәт икәнлеген күрсәтте;

2) Теориянең, аңлылыкның һәм стихияле эшчеләр хәрәкәтен революционлаштыручы һәм җитәкләүче көч булган партиянең әһәмиятен югары күтәрде;

3) Марксистик партия—эшчеләр хәрәкәтен социализм белән бергә кушу ул, дип иглан иткән төп марксистик положениене бик яхшы нигезләде;

4) Марксистик партиянең идеологик нигезләрен даһиларча эшләде“. („ВКП(б) тарихының кыскача курсы“, бит 44).

Лениннең шәкертләре Россиядә революцион социал-демократик оешмалар төзеделәр. Закавказьедә ленинчел-искрачы оешмага Л. Кецховели һәм С. Цулукидзе белән берлектә иптәш Сталин нигез салды. Турыдан-туры иптәш Сталин ярдәме белән Ладо Кецховели 1901 нче елны Бакуда яшрен типография оештырды, „Искра“ газетасының аерым номерлары да шушы типографиядә күчерелеп басылдылар. Сталин һәм Кецховели җитәкчелегендәге ленинчел-искрачы „Брдзола“ („Көрәш“) газетасы шушы яшрен типографиядә басылды.

Ул чагында ленинче „Искра“ тарафдарлары искрачылар дип йөртеләләр иде; 1903 нче елдан, партиянең II нче съездыннан, ягни Ленин пролетариат диктатурасы, партия уставы мәсьәләләре буенча, милли мәсьәлә буенча оппортунистларга каршы сугышка чыккан съездан башлап кына алар большевиклар дип йөртелә башладылар.

Ленин съездда „Искра“ның җиңүен тәэмин итү өчен бик күп көч куйды. Мартов, Аксельрод җитәчелегендәге тотнаксыз искрачылар, шулай ук Троцкий һәм съездның бөтен оппортунистик өлеше Ленинга һәм Ленинне яклаучы ныклы искрачыларга каршы кискен көрәш алып бардылар.

Программаны тикшергән вакытта оппортунистлар РСДРП программасына пролетариат диктатурасы турындагы пунктны кертүгә, крестьяннәр мәсьәләсе турындагы таләпләргә каршы чыктылар, милләтләрнең үз билгеләнүләренә каршы булдылар. Ленин бу каршылыкларның барсына җимергеч удар ясады. Съезд „Искра“ тәкдим иткән программаны кабул итте, бу эшчеләр сыйнфының революцион программасы иде.

Ләкин Ленинга партия уставы турындагы мәсьәлә буенча оппортунистларга каршы аеруча рәхимсез көрәш алып барырга туры килде. Уставның беренче параграфы—партиядә членлык турындагы параграфның формулировкасы өчен аеруча кискен фикер каршылыклары җәелде. Партия оешкан бер бөтен булырга тиешме яки нинди дә булса таркау, рәсмиләшмәгән булырга тиешме—съездда көрәш җәелгән мәсьәләнең эчтәлеге әнә шундый иде. Тотрыксыз искрачыларның ныклы искрачылардан аерылулары, аларның үзәк белән союзлары һәм ачыктан-ачык оппортунистларның аларга кушылулары Мартовка партиядә членлык турындагы мәсьәләне хәл иткән вакытта өстенлек биргән булсалар, партиянең үзәк учреждениеләре турындагы мәсьәлә буенча съезд үзенең тавыш бирүе белән Мартов тарафдарларының җиңелүен һәм Ленин тарафдарларының җиңүен нигытты. „Шул моменттан алып, съездда сайлаулар вактында күпчелек тавыш алган Ленин тарафдарларын большевиклар дип йөртә башладылар, Ленинга каршы булганнарны, азчылык тавыш алучыларны исә, меньшевиклар дип йөртә башладылар“ („ВКП(б) тарихының кыскача курсы“, бит 50).

Оештыру мәсьәләләре өлкәсендә II нче съезд тиешле югарылыкта булмады. Партиядә меньшевиклар изоляцияләнмәгәннәр иде, эшчеләр сыйнфы алдында фаш ителмәгәннәр иде. Бу бурыч хәтта съезд тарафыннан партия алдына куелмаган да иде. Менә шуңа күрә дә II нче съездан соң Ленин халыкара оппортунизм тарафыннан яклана торган меньшевикларга каршы иң кискен көрәш алып барды.

Ленин оппортунистларга каршы көрәштә „Бер адым алга, ике адым артка“ дигән атаклы китабын язды, бу китапта большевистик партиянең оештыру нигезләрен эшләде.

„Бу китапның әһәмияте барыннан да элек шуннан гыйбарәт ки, ул түгәрәкчелеккә каршы—партиялелекне яклады һәм таркатучыларга каршы—партияне яклады, организацион мәсьәләләрдә меньшевистик оппортуизмны тар-мар итте һәм большевистик партиянең организацион нигезләрен салды.

Ләкин аның әһәмияте моның белән генә бетми. Аның тарихи әһәмияте шуннан гыйбарәт ки, ул китапта Ленин пролетариатның җитәкче **оешмасы** булган, пролетариат кулында төп **корал** булган **партия турындагы тәглиматны** марксизм тарихында беренче тапкыр буларак эшләде, пролетариат диктатурасы өчен көрәштә шушы коралдан башка җиңәргә мөмкин түгел“ („ВКП(б) тарихының кыскача курсы“, бит 59). Мондый сугышчан эшчеләр партиясе Ленин тарафыннан нак Россиядә эшчеләр һәм крестьяннәр хәрәкәте киң дулкын булып җәелгән вакытта төзелде.

1904 нче елны рус-япон сугышы башланды. Патша революцияне сугыш белән буарга теләде. Ул моның киресенә иреште. Рус-япон сугышы революцияне тизләтте. Рус-япон сугышы вактында меньшевиклар оборончылык позициясенә тәгәрәделәр, ә Ленин һәм большевиклар сугышта царизмның җиңелүе царизмны көчсезләндерүгә һәм революцияне көчәйтүгә китерер дип санадылар. Шулай булды да.

Бу вакытта Ленин Швейцариядә эмиграциядә иде. 1905 нче елның 9 нчы январенда Петербургтагы канлы вакыйгаләр турында беренче хәбәрне ишетү белән үк Ленин: бу, Россиядә революциянең башлануы, диде.

Башланган революция социал-демократик партиягә гаять зур җаваплылык йөкләде. Үз көчләреңне оештырырга, көрәшнең формалары һәм юллары турында сөйләшергә кирәк иде. Ул вакытта „Искра“ газетасын, партия советын да меньшевиклар үз кулларына алдылар, ә партиянең II нче съездда сайланган Үзәк Комитеты тайпылышлы, дөрес булмаган юл алып барды. Ленин революциягә кадәр үк инде өченче съездны чакыруны таләп иткән булса, хәзер ул бу таләпне аеруча кискен рәвештә куйды. Россиядәге партия оешмаларының күпчелеге съездны тизрәк чакыру турындагы таләпне яклады. Иптәш Сталин җитәкчелегендәге Кавказ большевиклары съездга хәзерлек буенча аеруча зур эш үтәделәр.

1905 нче елның апрелендә, Лондонда РСДРП ның өченче съезды чакырылды. Бу беренче саф большевистик съезд иде. Меньшевиклар III нче съездга килүдән баш тарттылар. Лондондагы съезд белән бер үк вакытта алар Женевада үзләренең меньшевистик конференцияләрен ясадылар.

„Ике съезд—ике партия“,—Ленин хәлне әнә шулай билгеләде.

III нче съезд революция обстановкасында җыелды. Бөтен Россиядә забастовкалар, восстаниеләр бара иде. Съездда төп мәсьәләне: революциядә пролетариатның линиясе нинди булырга тиеш, революциядә эшчеләрнең җиңүен ничек тәэмин итәргә дигән мәсьәләне хәл итәргә кирәк иде. Ә моның өчен революциянең характерын һәм төрле сыйныфларның анардагы ролен дөрес билгеләргә кирәк иде.

III нче съезд үтү белән үк, 1905 нче елның июлендә, Ленин „Демократик революциядә социал-демократиянең ике тактикасы“ дигән китабын язды, монда ул меньшевикларның тактикасын тәнкыйтьләде һәм большевистик тактиканы даһиларча нигезләде. Большевикларның төп тактик положениесе Россиядәге буржуаз-демократик революциянең юлбашчысы һәм җитәкчесе пролетариат була ала һәм булырга тиеш, дигән положениедән гыйбарәт иде. Әгәр дә пролетариат үзенең союзнигын—крестьянлыкны үз ягына тарта ала революциянең юлбашчысы була ала.

Бу, буржуаз-демократик революциядә тактика мәсьәләләре буенча, буржуаз һәм социалистик революцияләр арасындагы чагыштырма буенча марксистик партиянең яңа установкасы иде, бу буржуаз-демократик революцияне социалистик революциягә үстерү турындагы Ленин тәглиматы иде.

9 нчы январьдан соң бөтен илдә эшчеләр хәрәкәте киң җәелде. Эшчеләрнең стачкалары бөтен илне дер селкетте. Шәһәр артыннан авыл да күтәрелә башлады. Изелгән милләтләр—поляклар, украинлылар, грузиннар, татарлар, еврейләр һәм башкалар арасында да азатлык хәрәкәте җәелде.

1905 нче елның июнендә „Потемкин“ броненосецында восстание башланды. Патша флоты морякларының бу восстаниесендә Ленин „самодержавиегә каршы революцион хәрәкәтнең үсешендә алга таба яңа һәм зур адым“ күрде (Ленин, әсәрләр, том VII, бит 379). Ленин кораллы восстание хәзерләү турындагы, вакытлы революцион хөкүмәт төзү турындагы мәсьәләне торган саен ныграк куя бара.

1905 нче елның көзендә революцион хәрәкәт бөтен илне чолгап ала. Ул гаять зур көч белән үсә.

1905 нче елның 30 (17) нче октябрендә патша манифест чыгара, революцион хәрәкәтнең үсүеннән куркуга төшкән патша бу манифестта сүздә халыкка гражданлык азатлыгының „какшамаслык“ нигезләрен бирергә вәгъдә итә, закон чыгару Думасы чакырырга вәгъдә итә.

Давыллы октябрь көннәрендә, эшчеләр массасының революцион иҗады көрәше утында яңа куәтле корал—Советлар төзелә. Петербургта һәм Москвада Советларның йогынтысы аеруча зур була.

Ноябрь башында Ленин Женевадан Швециягә, Стокһольмгә, ә аннан Финляндиягә, Гельсингфорска кайтырга чыга, чиктән ерак булмаган урында урнаша һәм яшрен рәвештә еш кына Петербургка кайта. Ноябрь ахрыннан башлап Ленин партиябезнең Петербург комитеты эшендә һәм башка комитетлар эшендә турыдан-туры эшлекле рәвештә катнаша. Ул җыелышларда речьләр сөйли; башка шәһәрләрдәге иптәшләр көрәшне ничек алып бару турында киңәшләшү өчен һәр вакыт аның янына киләләр.

Большевиклар, октябрь стачкаларыннан соң һәм 17 нче октябрь манифестыннан соң урнашкан һәм элеккегә караганда шактый ирекле булган тәртипләрдән файдаланып Петербургта легаль большевистик „Новая жизнь“ газетасын чыгара башлыйлар.

Ленин, царизмны корал белән бәреп төшерүгә халыклар массасын ничек хәзерләүне күрсәтә торган күп кенә мәкаләләр язды. 1905 нче елның декабрендә Ленин һәм Надежда Константиновна Крупская инде Петербургның үзендә урнашалар. Ләкин бу бик куркынычлы була, иптәшләре Ленинне Финляндиягә күчәргә үгетлиләр.

1905 нче елның декабрендә Финляндиядә, Таммерфорс шәһәрендә большевиклар конференциясе җыела. Бу конференциядә Ленин һәм Сталин беренче тапкыр очрашалар. Моңа кадәр алар хатлар белән генә үзара элемтә тоталар иде.

Таммерфорс конференциясендә Ленин белән үзенең беренче очрашуы турында искә алып иптәш Сталин болай дип язды:

„Лениннең бу конференциядә сөйләгән ике рече: агымдагы момент турындагы һәм аграр мәсьәлә турындагы речьләре, бик гүзәл булды. Алар, кызганычка каршы, сакланмаганнар. Болар бөтен конференцияне зур шатлыкка китергән дәртле речьләр иде. Ышандыру көченең гадәттән тыш зур булуы, аргументациянең гадилеге һәм ачыклыгы, кыска һәм һәр кемгә аңлаешлы фразалар, кыланууның юклыгы, тәэсиргә бәрә торган баш әйләндергеч кылануларның һәм эффектлы фразаларның юклыгы,—менә шуларның барсы белән Лениннең речьләре гадәттәге „парламент“ ораторларының речьләреннән уңышлы рәвештә аерылып тора иде.

Ләкин ул чакта мине сокландырган нәрсә, Ленин речьләренең бу ягы түгел иде. Мине, Ленин речьләрендәге, бер кадәр коры, ләкин аның каравы аудиторияне бик нык кулга ала торган, аны әкрен-әкрен электрлаштыра һәм соңыннан, бер нәрсәсен дә калдырмый, дигәндәй, үзенә бөтенләй әсир итеп ала торган җиңелмәс логика көче сокландырды“.

Москвада инде кораллы восстание башланды. Ленин киңәше буенча конференция үзенең эшен ашыгыч рәвештә тәмам итте һәм делегатларның күпчелеге восстаниедә актив катнашу өчен урыннарга таралдылар.

Ул чагында восстание Москвада гына булмады, ул барлык шәһәрләргә җәелеп, Балтык буе краен, Польшаны, Грузияне, Себерне чолгап алды. Патша хөкүмәте восстание башлаган районнарга җәза экспедицияләре җибәрде, бу восстаниеләрне ут һәм кан белән бастырды.

Кораллы восстание бастырылганнан соң революцион хәрәкәт кинәт кенә кимемәде. Революция әле тәмам булмады. Масса чигенергә теләмәде, масса әле һаман да көрәшкә омтылды. Ленин һәм Сталин аларны яңа революция өчен көч җыйнарга чакырдылар.

Уңышлырак көрәшү өчен эшчеләр бердәмлек, пролетариат партияләрен берләштерүне таләп иттеләр. Большевиклар эшчеләрнең бу таләпләрен якладылар һәм берләштерү съезды чакырырга меньшевикларга тәкдим иттеләр. Эшчеләр массасының басымы астында меньшевиклар риза булырга мәҗбүр булдылар. Партиянең берләштерелгән съездлары чакырылды: 1906 нчы елны Стокһольмдә IV нче съезд һәм 1907 нче елны Лондонда V нче съезд чакырылды.

Ленин меньшевиклар белән берләшүне бары тик большевистик карарлар нигезендә генә мөмкин дип санады.

Лениннең сугышчан җитәкчелегенең революция җиңелгәннән соң булган иң авыр елларда партиябезне саклап калу өчен гаять зур әһәмияте булды. Партия революциянең яңа күтәрелешен көтеп тору һәм җиңеп чыгу өчен үзенең тактикасын, үз-үзен тоту линиясен яңа эш шартларында үзгәртеп корды. Большевиклар революцион хәрәкәтнең яңа күтәрелеше өчен армый-талмый көч җыйнадылар.

Бу вакытта меньшевиклар буржуазиягә юл куюга барырга һәм патша режимына яраклашырга хәзер торалар иде, хәтта алар безнең партиябезнең яшрен оешмасын юк итәргә, бетерергә дип тә сөйләнделәр. Моның өчен аларны ликвидаторлар „Столыпин эшчеләр партиясе“ дип атадылар.

Башка ликвидаторлар кебек үк Троцкий да подпольедәге партиягә һәм социал-демократиянең революцион лозунгларына каршы булды. Ул ликвидаторлыкны большевикларны меньшевиклар белән „килештерү“ һәм „берләштерү“ фразалары белән капларга маташты. Ленин Троцкийны „Иудушка“ дип атады, троцкизм—ул, ликвидаторлыкның иң әшәке төре, диде. Иптәш Сталин да үзенең Сольвычегодскийдан Ленинга язган хатында троцкизмга шундый ук кискен бәя бирде.

Ленин сугышчан партиябезне саклап калу өчен меньшевик-ликвидаторларга каршы кискен көрәш алып барды. Партиябезнең полиция тарафыннан бик каты эзәрлекләнүе шартларында эшләргә туры килде. Күп кешеләргә, шул исәптән Ленинга да, яңадан эмиграциягә китәргә туры килде.

Лондон съездыннан соң Ленин тагын бер тапкыр Финляндиягә кайтты. Бу вакытта большевикларның бер өлеше илдәге үзгәргән шартларда царизмга каршы көрәшнең яңа юлларына таба борылырга кирәклекне аңламады. Алар кораллы восстаниегә хәзерлек турында сөйләүләрендә дәвам иттеләр, Дәүләт Думасына большевикларның бойкот иглан итүләрен таләп иттеләр. Ә инде Дәүләт Думасына депутатлар сайланганнан соң бойкотны яклаучыларның бер өлеше бу депутатларны Думадан чакырып алуны таләп итте. Моның өчен аларны „отзовистлар“ дип атадылар. Алар безнең иптәшләребезне хәтта профессиональ союзлардан һәм ачыктан-ачык хәрәкәт итүче башка оешмалардан да чакырып алуны таләп иттеләр. Ленин аларны „тискәре як ликвидаторлар“ дип атады.

Авыр реакция елларында, революциянең җиңелүе һәм партиядән киткән интеллигентларның ревизионистлык чыгышларының көчәюе шартларында большевиклар партиянең байрагын ташламадылар, партиянең марксистик программасына турылыклы булуларын саклап калдылар һәм марксистик теория „критиклары“ның атакаларын кире кактылар. Ленин партияне һәм аның революцион принципларын марксизм дошманнарының һөҗүмнәреннән саклап калды.

Лениннең 1909 нчы елны басылып чыккан „Материализм һәм эмпириокритицизм“ дигән атаклы китабы Маркс һәм Энгельс үлгәннән соң фән тарафыннан табылган барлык иң әһәмиятлеләргә йомгак ясады. Бу китап шулай ук марксизм-ленинизмның теоретик нигезләрен яклау булды.

1909 нчы елның җәендә, Лениннең таләп итүе буенча, „тискәре як ликвидаторлар“—„отзовистлар“, „алла төзүчеләр“ һәм марксизм дошманнары булган барлык башка идеалистлар большевиклар сафларыннан куылдылар. Шулай ук Ленин, килешүчәннәрне—Троцкий агентларын: Зиновьевны, Каменевны, Рыковны һәм башкаларны да рәхимсез рәвештә фаш итте. Болар большевикларны ликвидаторлар белән буташтырырга теләгәннәр иде.

1907 нче елның азагында Ленин яңадан чит илгә (башта Стокһольмгә—Швециягә, соңыннан Берлингә—Германиягә һәм аннары Женевага—Швейцариягә) күчеп китәргә мәҗбүр булды. Ул чагында партиябезнең үзәк органы булган „Пролетарий“ газетасында ул эшчеләр хәрәкәтенең бу дошманнарына каршы көн саен көрәш алып барды һәм бу авыр заманда көрәшнең дөрес юлын табуда эшчеләр сыйнфына ярдәм итте. Париж якынында (Лонжюмо бистәсендә) Ленин партия мәктәбе оештырды (1911 нче елны). Анда безнең Россиядәге иптәшләребез, алдынгы эшчеләр килделәр, алар Ленин җитәкчелегендә революцион эшкә хәзерләнү өчен яшрен рәвештә чик аркылы үтеп чыгалар иде.

Бу гаять авыр чорда Ленин партиянең көчләрен җыйнады. Ул Плеханов белән блок төзеде. Бу чорда Плеханов партиянең яшрен оешмасын саклау ягында тора иде һәм ликвидаторларга каршы көрәш алып бара иде.

1912 нче елның январенда чит илдә, Прагада партиянең Бөтенроссия конференциясе чакырылды. Партияне ликвидаторлардан тәмам чистартырга кирәк иде.

*(ДӘВАМЫ 3 нче БИТТӘ).*

В. И. Ленин, И. В. Сталин һәм К. Е. Ворошилов иптәшләр карта янында. Художник В. Васильев рәсме.

# ВЛАДИМИР ИЛЬИЧ ЛЕНИН

*(ДӘВАМЫ)*

Меньшевиклар һәм „сул“ ликвидаторлар белән араны чынлыкта өзүне ахрынача илтеп җиткерергә һәм аерым партия булып—Көнбатыштагы социал-демократик партияләрдән аермалы булган, оппортунистлардан азат булган, пролетариатны власть өчен көрәшкә алып барырга сәләтле булган яңа тип партия булып оешырга кирәк иде. Бу бурычны Прага конференциясе үтәде. 1912 нче елның январенда Прага конференциясендә партиянең Үзәк Комитеты сайланды, аңа Ленин, Сталин, Свердлов, Орджоникидзе, Калинин, Спандарьян иптәшләр һәм башка большевиклар керде.

Бу вакытта Россиядә революцион хәрәкәтнең яңа күтәрелеше, революцион дулкынның яңа күтәрелеше ачык билгеләнде. Большевиклар, Петербургта ачыктан-ачык үзләренең эшче газеталарын—башта „Звезда“ ны, ә соңыннан „Правда“ ны чыгара башлауга ирешә алдылар.

„Правда“ да иптәш Сталин күп язды. Ул аның редакторларыннан һәм оештыручыларыннан берсе иде. „Правда“ редакциясенең секретаре иптәш Молотов булды.

Ленин чит илдә торып, партиянең юлбашчысы буларак, безнең газеталарыбызга җитәкчелек итте, аларга юнәлеш бирде, аларны дөньяда пролетариатның иң сугышчан партиясенең сугышчан коралы итте.

Шулай ук Ленин эшче депутатларның Дәүләт Думасындагы чыгышларына да җитәкчелек итте. Ул, шулай ук Сталин да, алар өчен хатлар яздылар, ничек эш итәргә, Дәүләт Думасында тикшерү өчен нинди мәсьәләләрне күтәрергә кирәклек турында киңәшләр бирделәр.

Ленин һәм бөтен большевиклар партиясе пролетариатның барлык сугышчан көчләрен җыйнаганда, туплаганда, Троцкий 1912 нче елны большевикларга каршы көрәшү өчен „Август блогы“ дип аталган нәрсәне оештырды. Бу союзга большевизмга дошман булган барлык социал-демократик агымнар һәм группалар керделәр. Троцкий меньшевикларга аларның пролетар партиягә каршы көрәшләрендә ярдәм итте, вак интригалар белән шөгыльләнде, гайбәт сатты, большевикларга яла якты. Ленин Троцкийга каршы рәхимсез көрәш алып барырга тиеш булды. Ул аны ике йөзлелеге өчен, бушкалыгырдавы өчен „Иудушка“, „Балалайкин“ дип атады. Троцкийның партиягә каршы элементлардан блок төзү юлындагы барлык маташулары ул чагында да тулы уңышсызлык белән тәмам булды. Большевиклар Ленин җитәкчелегендә җиңделәр һәм эшчеләр сыйнфын үз артларыннан алып киттеләр.

1912 нче елның 17 (4) нче апрелендә ерак Себер тайгасында, Ленадагы алтын приискаларында стачка вактында, патшаның жандарм офицеры приказы буенча 500 дән артык эшче үтерелде һәм яраланды. Лена вакыйгаләре бөтен илдә киң массовый революцион хәрәкәтнең башлануы булып хезмәт иттеләр.

Дәүләт Думасындагы большевик депутатлар царизмның Лена приискаларындагы җинаяте турындагы мәсьәләне кыю рәвештә куйдылар.

Ул вакытта (1912 нче елның җәендә) Ленин Россия чигенә якынрак булу һәм Россиядә эшләүче иптәшләр белән ешрак хәбәрләшергә мөмкинлек алу өчен Краковка күчеп килде. Анда ул бер ел диярлек торды.

Хәзер инде Ленин „Правда“ да һәм „Просвещение“ журналында мәкаләләр белән көн саен диярлек чыгарга мөмкинлек алды. Ленин, гади, ачык тел белән, чын күңелдән әйтелгән гади сүзләр белән, революцион вакыйгаләрнең мәгнәсен аңлатты, көрәшнең чын юлын күрсәтте.

Ленин һәм Сталин пролетар революция чорында милли мәсьәләнең гаять зур әһәмияте булачагын алдан күрделәр, аны пролетариат диктатурасы турындагы гомуми мәсьәләнең бер кисәге итеп эшләделәр. Ленин ике зур әсәр язды: „Милләтләрнең үз билгеләнүләре хокукы“ һәм „Милли мәсьәлә буенча тәнкыйть язмалары“. Шул ук вакытта (1913 нче елны) иптәш Сталин „Марксизм һәм милли мәсьәлә“ дигән зур әсәрен язып большевистик „Просвещение“ журналында бастырды. Ленин бу әсәргә бик югары бәя бирде.

1912 нче елны Ленада булган атудан соң башланган һәм бөтен Россияне диярлек чолгап алган массовый стачкалар 1914 нче елгы империалистик сугыш игълан ителгәнгә кадәр тукталмадылар. Эшчеләр сыйнфы һөҗүмгә күчте.

Бу авыр хәлдән царизм вакытлыча котылу юлын 1914 нче елның августында башланган империалистик сугыштан тапты.

Бу вакытта Ленин Австро-Венгриядә, Поронино авылында тора иде. Владимир Ильичне кулга алдылар һәм төрмәгә утырттылар. Надежда Константиновнаның һәм кайбер социалистларның тырышлыгы белән Ленинне азат иттеләр һәм ул сугышка каршы үзенең революцион эшен дәвам иттерү өчен Швейцариягә күчеп китте.

Башланган сугышның империалистик характерын бөтен рәхимсезлек белән ачкан бердән-бер партия Ленин тарафыннан тәрбияләнгән большевиклар партиясе булды. Сугыш башлану белән үк большевиклар партиясенең Үзәк Комитеты барлык эшчеләргә, крестьяннарга, барлык хезмәт ияләренә карата мөраҗәгат чыгарды. Анда ул Россиянең хезмәт ияләре массасы өчен „иң ким явызлык (наименьшее зло) патша монархиясенең, Европадагы һәм Азиядәге иң күп сандагы милләтләрне һәм иң күп халык массасын изүче иң реакцион һәм иң варвар хөкүмәтнең, җиңелүе булыр иде“ диде. Ленин җитәкчелегендәге большевиклар бу җиңелүнең революциягә китерәчәген белделәр. Большевиклар партиясенең Үзәк Комитеты Россиядә „Бетсен сугыш!“, „Сугышка каршы сугыш!“, „Яшәсен революция!“ дигән лозунглар бирде.

Ленин Швейцариядән Россиягә үзенең сугыш турындагы тезисларын җибәрә. Шуның белән бергә ул, һәрбер аерым илдә сугышны алып баруда үз буржуазияләренә ярдәм итү ягында торучы оборончыларга каршы көрәш башлый. Плеханов җитәкчелегендәге меньшевиклар әнә шундый оборончылар булалар.

Ленин II нче Интернационалның, эшчеләр сыйнфының революцион оешмасы булу ягыннан инде үлгәнлеген күрде, һәм шуңа күрә 1914 нче елның ноябрендә инде Ленин яңа, III нче Интернационалны, Коммунистик Интернационал төзүне төп бурыч итеп куйды. Империалистик сугыш вактында Ленин барлык илләрдә эшчеләр сыйнфының яңа революцион оешмасын төзи алырлык кешеләрне җыя белде. 1915 нче елның сентябрендә, Швейцариядәге Циммервальд авылында, сугышка каршы чыгучы социалистларның беренче киңәшмәсе җыелды, анда Ленин эшлекле төстә катнашты. 1916 нчы елның августында Ленин Кинтальдә (Швейцария) барлык илләрдәге социалистларның киңәшмәсендә катнашты. Сугыш вактында Ленин үзенең иң гүзәл китапларыннан берсен—„Империализм—капитализмның югарыгы стадиясе“ дигән китабын язды. Бу китабында Ленин империализмга капитализм үсешенең соңгы стадиясе сыйфатында анализ ясап, капитализмның тигезсез үсүе аркасында империалистик сугышлар килеп чыгуны, аларның капитализмны йомшатуларын һәм империализм чылбырының барыннан да бигрәк йомшак булган бер буынында өзелүе мөмкин итүләрен күрсәтте. Иптәш Ленин 1915 нче елны язылган әсәрләрендә үк инде социализмның башта аерым алынган бер яки берничә илдә җиңүе мөмкинлеген исбат итте. Бу—социалистик революция турында тәгәлләнгән яңа теория иде.

1917 нче елның 16 нчы апрелендә—Россиядә февраль революциясе булганнан соң ике айдан да кимрәк вакыт үткәч—Ленин эмиграциядән кайтты. Петербургта гаять күп эшчеләр, солдатлар һәм матрослар массасы большевиклар партиясенең юлбашчысын каршылау өчен Финляндский вокзалга килделәр. Ленин вокзал янында броневиктан торып речь сөйләде һәм „Яшәсен бөтен дөнья социалистик революциясе!“ дигән сугышчан лозунг бирде.

Петроградка кайтканнан соң икенче көнне үк, 17 (4) нче апрельдә Ленин эшче һәм солдат депутатлары Советларының Бөтенроссия конференциясе членнары булган большевиклар киңәшмәсендә чыгып сөйләде, ә соңыннан докладның тезисларын большевиклардан башка меньшевиклар да булган җыелышта кабатлады. Болар Лениннең атаклы Апрель тезислары иде. Лениннең Апрель тезислары буржуаз-демократик революциядән социалистик революциягә күчү өчен партиянең даһи көрәш планын билгеләделәр. Буржуазия тезгенендә баручы, капитализмны саклап калу ягында торучы Каменев, Рыков һәм башка хиянәтчеләр Ленин тезисларына каршы чыктылар. Большевиклар Ленин тирәсенә тупландылар, аның тезисларын сугышчан хәрәкәт программасы итеп алдылар. Миллионнарча эшчеләр, солдатлар һәм крестьяннәр большевиклар ягына чыга башладылар.

Петроградта йөзләрчә мең эшчеләрнең һәм солдатларның июнь—июль чыгышлары (1917 нче ел) Ленин лозунгларының, партиябез лозунгларының иң киң масса тарафыннан элеп алынганлыгын күрсәттеләр. „Бөтен власть Советларга!“, „Бетсен капиталист министрләр!“. Бу лозунглар барлык байракларга язылдылар.

Вакытлы хөкүмәт, меньшевиклар һәм эсерлар ярдәме белән, иң әшәке адымга барырга булды: ул Ленинне һәм большевиклар партиясе Үзәк Комитетының башка членнарын кулга алырга карар бирде. Күп кенә иптәшләр, шул исәптән Үзәк Комитет членнары да кулга алындылар.

Контрреволюцион буржуазия судына Лениннең бармаска тиешлеге турында Үзәк Комитет иптәш Сталинның такдимен кабул итте. Ленинне Петроград янындагы Разлив станциясе янына яшерделәр.

Ленин шалашта яшренеп, „Большевиклар дәүләт властен тотып кала алырлармы?“ дигән брошюрасын язды. Анда ул восстаниегә җитәкчелек итү буенча партиябезнең төп бурычларын һәм властьны алганнан соң пролетар дәүләтнең беренче адымнарын тулы итеп билгеле.

Вакытлы хөкүмәт шпионнары тарафыннан эзәрлекләнгән Владимир Ильич Партиянең 1917 нче елның июль азагында—август башында булган VI нчы съездында катнаша алмады, ләкин ул аңа үзенең көрәштәшләре—Сталин, Свердлов, Молотов, Орджоникидзе аркылы подпольедән торып җитәкчелек итте.

Съездда иптәш Сталин үзенең докладында революциянең үзенең характеры буенча социалистик булып баруын, хәзер инде революциянең тыныч үсеше мөмкин түгеллекне, властьны көч белән алырга, Вакытлы хөкүмәтне бәреп төшерергә кирәклекне күрсәтте. Партиянең алтынчы съезды партияне коралллы восстаниегә, социалистик революциягә юнәлдерде. Съезд Россиядә пролетар революциянең булуы мөмкин түгеллек турында Преображенскийның һәм Бухаринның троцкича раслауларын бердәм рәвештә кире какты. Иптәш Сталин үзенең чыгышында болай диде:

„Нак менә Россиянең социализмга юл салучы ил булу мөмкинлеге бар... Безгә бары тик Европа гына юл күрсәтә ала дигән иске карашны ташларга кирәк. Догматик марксизм һәм иҗади марксизм бар. Мин соңгысы җирлегендә торам“ (РСДРП(б) ның VI нчы съезды протоколлары, 233—234 нче битләр).

Контрреволюцион Вакытлы хөкүмәт һәм ак гвардеецлар Ленинне бик тырышып эзләделәр. Ленинне котырган ак гвардеецлардан коткару өчен аны Финляндиягә күчерергә карар бирелде. Владимир Ильич Гельсингфорска барып урнашты. Анда ул үзенең „Дәүләт һәм революция“ дигән зур әсәрен тәмам итә. Революцион вакыйгаләр яшен тизлеге белән җәеләләр. Ленин Петроградка якынрак булу өчен Гельсингфорстан Выборгка күчеп килә.

16—20 нче октябрьдә Ленин бик тизлек белән властьны алырга чакырып Үзәк Комитетка, Москва һәм Петроград комитетларына, Питер һәм Москва советларының большевик членнарына хатлар җибәрә.

20 (7) нче октябрьдә Ленин Петроградка күчеп килә һәм 23 (10) нчы октябрьдә Үзәк Комитет, Ленин такдиме белән, коралллы восстание турында карар кабул итә. Хиянәтче Зиновьев һәм Каменевлар Үзәк Комитет карарына каршы чыгалар. Алар хиянәтчел төстә Үзәк Комитетның коралллы восстание турындагы яшрен карарын контрреволюцион буржуазиягә белдерәләр, восстаниенең планын һәм срокларын дошманга белдерәләр. Ленин Үзәк Комитетка махсус хат язып контрреволюциянең бу кабахәт булышчыларын партиядән чыгаруны турыдан-туры таләп итте. Ленин һәм Сталин восстаниене хәрби-техник яктан хәзерләүне инкар иткән һәм коралллы чыгышның кайчан булачагын буржуазиягә белдергән Троцкийның хиянәтенә каршы кискенлек белән чыгалар.

6 нчы ноябрьдә Ленин Үзәк Комитет членнарына яңадан хат яза һәм бик тизлек белән коралллы чыгыш ясауны таләп итә.

6 нчы ноябрьдә төнлә Ленин танылмаслык булып киенеп, Смольныйга, хәрби-революцион комитет штабына килде һәм анда иптәш Сталин белән берлектә, башланган восстаниегә турыдан-туры сугышчан төстә җитәкчелек итүгә шунда ук кереште. Большевиклар 7 нче ноябрьгә (25 нче октябрьгә) каршы төндә бик тиз генә Петроградтагы барлык иң әһәмиятле пунктларны: телеграфны, телефонны, Петропавел крепостен алдылар, Кышкы сарайны алып, анда Вакытлы хөкүмәтне кулга алдылар һәм юнкерларны тар-мар иттеләр. Ленин һәм Сталин иптәшләр Смольныйдан торып коралллы восстаниегә җитәкчелек иттеләр.

7 нче ноябрьдә Россиянең барлык гражданнарына карата Ленин тарафыннан язылган мөраҗәгат игълан ителде. Анда Петроград советының хәрби-революцион комитеты түбәндәгечә белдерү ясады: „Вакытлы хөкүмәт төшерелде. Дәүләт власте эшче һәм солдат депутатларның Петроград советы органы кулына—Петроград пролетариатының һәм гарнизонының башында торучы хәрби-революцион комитет кулына күчте“.

8 нче ноябрьдә Советларның II нче съезды, Ленин такдиме буенча, солых турындагы һәм җир турындагы декретларны кабул итте. Бу соңгысы буенча алпавытларның җиргә хуҗа булулары һичбер түләүсез бик тизлек белән бетерелә.

Төнлә Эшче-Крестьян хөкүмәтен—Халык Комиссарлары Советын төзү турында карар кабул ителде. Совнарком җитәкчелегенә В. И. Ленин куелды. Милләтләр эшләре буенча халык комиссары итеп И. В. Сталин сайланды.

Шул вакыттан алып Россиянең яңа тарихы, пролетар хәрәкәтнең яңа тарихы, бөтен дөнья социалистик революциясе тарихы башланды.

Бөтен иске дөнья большевикларга каршы тупланды.

Шунлыктан властьны алган большевиклар алдына беренче моменттан ук хуҗалык һәм хәрби тәртиптәге зур кыенлыклар килеп басты. Аннан соң бөтен иске дәүләт аппаратын, бөтен иске дәүләт машинасын ватарга кирәк булганга күрә дә гаят зур илне идарә итү кыен иде. Совет власте хуҗалыкны идарә итүне эшчеләр кулына тапшырган чараларны бер-бер артлы үткәрде.

Шул ук вакытта илнең оборонасын да күтәрергә кирәк иде. Пролетар диктатура аппараты, дәүләтне идарә итүче яңа аппарат, яңа дәүләт машинасы төзүгә, социалистик хуҗалык оештыруга һәм Кызыл Армияне төзүгә Владимир Ильич Ленин җитәкчелек итте.

Ленин революциягә чын күңелдән бирелгән эшче һәм крестьяннәр ярдәменә таянып данлыклы сугышчан партиябезгә җитәкчелек итте, эшчеләрнең һәм крестьяннәрнең беренче дәүләтен оештырды.

Илебез социалистик хуҗалык төзи башлады һәм техник яктан күп тапкырлар көчлерәк булган күп санлы дошманнардан уңышлы рәвештә сакланды. Дошманнар һәр кайда да башларын күтәрделәр. Сугыш әле бетмәгән иде. Ленин, кулны чишеп җибәрү өчен, сугыштан котылу һәм тын алу өчен, авыр булса да, килешүгә барырга кирәк дип санады.

Меньшевиклардан һәм эсерлардан алып, иң явыз ак гвардеецларга кадәр барлык контрреволюционерлар солых төзүгә каршы котырынган агитация алып бардылар. Аларның юлы ачык иде: алар солых сөйләшүләрен өзәргә, Германия империалистлары ярдәме белән Совет властен юк итү өчен немецләрнең һөҗүмен китереп чыгарырга теләделәр.

Бу кара эштә Троцкий һәм аның ярдәмчесе Бухарин аларның союзниклары булдылар. Радек һәм Пятаков белән берлектә Бухарин партиягә дошман булган һәм үзен яшерү өчен „сул коммунистлар“ группасы дип аталган группага җитәкчелек итте.

1918 нче елның 10 нчы февралендә Брест-Литовскийда солых сөйләшүләре өзелде. Ленин һәм Сталин солыхка кул куюны таләп итүгә дә карамастан, Троцкий, совет делегациясе председателе буларак, хиянәтле төстә большевиклар партиясе Үзәк Комитетының турыдан-туры директиваларын бозды.

„23 нче февральдә Үзәк Комитет немецләр командованиесенең шартларын кабул итәргә һәм солых договорына кул куярга карар чыгарды. Троцкийның һәм Бухаринның хиянәтләре Советлар республикасына кыйммәткә төште“ („ВКП(б) тарихының кыскача курсы“, 246 нчы бит).

1918 нче елның 6 нчы мартында партиянең VII нче съезды чакырылды. Съезд Лениннең бик тизлек белән солых төзү турындагы резолюциясен кабул итте.



Сулда—В. И. Лениннең бала чагы. Унда—В. И. Лениннең 1887 нче елда гимназиядә укыган чагы.

Лениннең һәм безнең бөтен партиябезнең ныклы омтылышы белән героик Кызыл Армия төзелде. Аны Ленин, Сталин, Ворошилов, Фрунзе оештырды. Кызыл Армия дошманнарны тар-мар итте. Моңа чит ил армияләрендә безгә каршы җибәрелгән эшчеләрнең һәм крестьяннәрнең безнең якта булулары да ярдәм итте.

Ләкин бу җиңү берьюлы гына килмәде. Тик 1919 нчы елны гына совет гаскәрләре, иптәш Сталин эшләгән планны кулланып, Уралда Колчакны тар-мар иттеләр һәм аны тагын да арырак, көньчыгышка, Иркутскига кадәр куып бардылар, анда Колчак пленгә алынды һәм атылды. Шуннан күп соңрак большевиклар көнчыгыштан япон гаскәрләрен кудылар; Дутовны, Красновны да, Петлюраны да, кулак бандит Махноны да тар-мар иттеләр. Кызыл Армия, Сталин планы белән кулланып эш итеп, турыдан-туры иптәш Сталин җитәкчелегендә, Деникинны һәм Юденичны тар-мар итте. Төньяктан да, көньяктан да, көнчыгыштан да, көнбатыштан да—һәр җирдә дә империалистларны кудык. Безнең соңгы көрәшебез Польша фронтында һәм барон Врангельгә каршы Кырымда булды. Кызыл Армия барон Врангельны да тар-мар итте. Антанта империалистларының өч походы әнә шулай туздырылды.

Совет властеның явыз дошманнары—алпавытлар, капиталистлар һәм кулаклар, капиталистларга, алпавытларга һәм кулакларга ярдәм иткән эсерларның һәм меньшевикларның вак буржуаз партияләре Совет властен бетерергә, Ленинне юк итәргә план кордылар. Эсерлар Ленинне үтерергә карар бирделәр.

„Уң-троцкичы үзәк“ процессы материалларыннан күренгәнчә, эсерлар бу коточкыч явыз эшне Бухарин һәм Троцкий белән килешеп эшләргә уйлаганнар.

1918 нче елның 30 нчы августында Ленин Замоскворечье районында элекке Мехельсон заводында (хәзер Ильич исмендәге завод) митингта чыгып сөйләде. Көчле кул чабулар астында Ленин трибунадан төште. Ленин эшчеләр белән исәнләшеп, автомобильгә утырырга торганда эсерка Каплан аңа дүрт тапкыр атты.

Ленин авыр яраланды. Бөтен ил Лениннең авыруы барышын тирән игътибар белән күзәтеп торды. Әгәр дә Лениннең нык тазалыгы булмаса иде, ул авыр яралануга түзә алмаган булыр иде.

Лениннең терелүе турындагы беренче хәбәр бөтен ил өчен гаят зур шатлык булды. Ленин яңадан безнең белән, без җиңәчәкбез!

III нче Коммунистик Интернационалны төзү Лениннең иң бөек хезмәте булды. Коммунистик Интернационалны оештыруда Ленингә аның партиябезнең Үзәк Комитетындагы иптәшләре ярдәм иттеләр, бу эштә аңа барлык илләрдә пролетариатка чын күңелдән бирелгән революционерлар ярдәм иттеләр, аңа безнең бөтен партиябез ярдәм итте.

Ленин III нче Интернационалның нигезләрен социал шовинистларга һәм центристларга каршы кискен көрәштә салды. Ленин, интернационалистларны берләштереп, II нче Интернационалдагы сулларның эзлексезлеген, аларның ярым меньшевистик ялгышларын тәнкыйть итте, сулларны оппортунизм белән араны өзәргә этәрде.

Коммунистик Интернационалның I нче съезды (конгрессы) 1919 нчы елның мартында Москвада чакырылды. 6 нчы мартта Ленин Коммунистик Интернационалның төзелүе турында речь белән чыкты.

Ленин тарафыннан төзелгән Коммунистик Интернационал Ленин исән чагында бөек көч булып әверелде, Ленин үлгәннән соң ул тагын да дәһшәтле көч булып үсте.

Гражданнар сугышы бетте. Советлар иле тыныч хуҗалык төзелеше юлларына күчә башлады. Кыенлыклар бик зур иде. Дүрт еллык империалистлык сугыш һәм интервенциягә каршы өч еллык сугыш аркасында халык хуҗалыгы җимерелгән иде.

Гражданнар сугышы утында эшчеләрнең һәм крестьяннәрнең союзы ныгыды. Хәрби коммунизм гражданнар сугышында җиңүне тәэмин итте. Ләкин сугыш бетте һәм хәрби коммунизм политикасы инде совет халкының бурычларына туры килми башлады. Көрәш юлын үзгәртергә кирәк булды.

Хәрби коммунизм шәһәрдә һәм авылда капиталистик элементлар крепостен штурм белән алырга тырышу булды. Ленин, „штурм“нан „камап алу“га күчәргә кирәклекне күрсәтте. Ленин азык разверсткасын бетерергә һәм азык налогы урнаштырырга, икмәк белән һәм башка продуктлар белән иркле сәүдә итүгә рөхсәт бирергә, сәүдәне яхшырак итеп оештырырга, кооперацияне үзгәртеп корырга такдим итте.

„Ленин болай дип санады: товар оборотының беркадәр иркле булуы крестьяндә хуҗалык белән кызыксыну тудырыр, аның хезмәтенең җитештерүчәнлеген күтәрер һәм авыл хуҗалыгын тизлек белән күтәрүгә алып барыр, шушы нигездә дәүләт промышленносте аякка бастырылыр һәм хосуси капитал кысрыклап чыгарылыр, көчләр һәм средстволар тупланганнан соң, социализмның экономик нигезе булган куәтле индустрияне төзергә, һәм аннан соң илдә капитализм калдыкларын бетерү өчен кискен һөҗүмгә күчәргә мөмкин булыр, диде“ („ВКП(б) тарихының кыскача курсы“, 290—291 нче битләр).

Илебезнең тормышы өчен бу җаваплы моментта, Троцкий җитәкчелегендәге группалар яңадан партиягә каршы көрәш башладылар.

1921 нче елның мартында партиянең X нчы съезды яңа экономик политикага күчү турында Ленин такдимен тулысынча кабул итте. Бөтен партия, бөтен ил Ленинне яклады һәм алар аның тарафыннан такдим ителгән яңа экономик политиканы үткәрә башладылар.

Бары бер ел үтте, ә илдә хәл шул кадәр яхшырды, 1922 нче елны инде Ленин чигенүнең беткәнлеген һәм безнең яңа һөҗүм башлавыбызны белдерә алды. Яңа һөҗүм капитализмның барлык калдыкларына каршы, кулакларга каршы, хуҗалыкны тулысынча социалистик үзгәртеп кору өчен барды. Сугыш тарафыннан җимерелгән хуҗалыкны иске нигездә аякка бастырып булмый иде, бөтен экономикабызга яңа фундамент салырга кирәк иде. Бу фундамент яңа техника иде. Аны төзергә кирәк иде. Электрлаштыру буенча беренче ун еллык план төзелде. Илебезгә электр яктылыгы, арзанлы хәрәкәт көче, арзанлы ягулык бирү өчен бөтен илдә куәтле электр станцияләре төзү планы эшләнде. Лениннең хуҗалык планының аерылмас өлеше кооперациянең иң югары формасы сыйфатында авыл хуҗалыгын коллективлаштырудан гыйбарәт булды.

*(АХРЫ 4 нче БИТТӘ).*

# ВЛАДИМИР ИЛЬИЧ ЛЕНИН

*(АХРЫ. БАШЫ 1, 2 һәм 3 нче БИТЛӘРДӘ).*

„Ленин гомумән кооперациядә, бигрәк тә авыл хуҗалыгы кооперациясендә, вак игезәк хуҗалыклардан товарищество нигезендәге эре производство берләшмәләренә—колхозларга күчүнең миллионнарча крестьяннар ирешә алырлык һәм аңлаешлы юлын күрде. Ленин болай дип күрсәтте: безнең илебездә авыл хуҗалыгының үсеше крестьяннарны кооперация аркылы социалистик төзелешкә тарту юлы белән, товар урнаштыру (сбыт) өлкәсендә, ә аннан соң авыл хуҗалыгы продуктларын житештерү өлкәсендә авыл хуҗалыгына әкренләп коллективизм нигезләрен кертү юлы белән барырга тиеш. Ленин болай дип күрсәтте: пролетариат диктатурасы һәм эшчеләр сыйныфының крестьяннар белән союзы вакытында, пролетариатның крестьяннарга карата житәкчелеген тәэмин иткән вакытта, социалистик промышленность булган вакытта, дөрес оештырылган, миллионнарча крестьяннарны чолгап ала торган производство кооперациясе шундый средство булып тора ки, бу средство ярдәме белән безнең илебездә тулы социалистик җәмгыят төзеп житкерергә мөмкин" („ВКП(б) тарихының кыскача курсы", 296 нчы бит).

1919 нчы елның мартында партиянең VIII нче съездында, авылда эшләү турындагы докладында Ленин болай диде: „Әгәр дә без иртәгә беренче класслы 100 мең трактор бирә алсак иде, аларны бензин белән тәэмин итә алсак иде, аларны машинистлар белән тәэмин итә алсак иде (сез беләсез бу хәзергә — фантазия), ул чагында урта хәлле крестьян: „Мин коммуния (ягни коммунизм) яклы" дияр иде". (Том XXIV, бит 170). Иптәш Сталин җитәкчелегендә партия Лениннең хыялын чынбарлыкка әйләндерде. Хәзер социалистик кырларда йөз мең түгел, бәлки 500 мең беренче класслы тракторлар, 200 мең автомобиль һәм шул кадәр үк диярлек комбайннар һәм башка төрле катлаулы авыл хуҗалыгы машиналары эшли. Крестьян хуҗалыкларының 90 процентан артыгы коллективлашты. Тоташтан коллективлаштыру нигезендә партия һәм Совет власте илебездә соңгы капиталистик сыйныфны—кулакларны бетерделәр. Бу, үзенең нәтиҗәләре ягыннан 1917 нче елгы Октябрь перевороты белән бер дәрәҗәдәге бөек революцион переворот булды.

⁂

**Ленин барлык халыкларның дусы иде.** Патша Россиясе халыклар төрмәсе булды. Анда тигезсезлек, күп халыкларның изелүе яшәп килде.

Ленин бөтен гомере буена төрле милләтләрнең эшчеләр сыйныфын һәм хезмәт ияләрен, **барлык милләтләрне гомуми бер союзга** берләштерү өчен көрәште.

Ленин пролетариатның иң бөек вәкилләренең, остазларыбыз булган Маркс һәм Энгельсның „башка халыкларны изүче халык азат була алмый" дигән сүзләрен еш кына искә ала иде.

Совет дәүләтендә барлык милләтләр үзләренә азат тормыш төзү мөмкинлеге алдылар. Бу эштә Лениннең Совет властеның беренче елларында милләтләр эшләре халык комиссары булган һәм СССР халыкларының бөек дуслыгын тудыру өчен күп эшләгән иптәш Сталин зур булышлык күрсәтте.

Ленин алып барган гаять зур эш, подпольеда үк кичергән мохтаҗлыклар, кулга алынулар, сөргеннәр, 1918 нче елның 30 нчы августында эсерларның аны яралавы аның сәламәтлеген бик нык какшаттылар.

1922 нче елның маеннан В. И. Ленин авырый башлады. Беркадәр сәламәтләнгәннән соң аның авыруы кабат көчәйде. 1924 нче елның 21 нче январенда, кич 6 сәгать 50 минутта Ленин үлде.

1924 нче елның 23 нче январе—Лениннең Горкидан Москвага соңгы юлы. Бөтен бөек Советлар иле, җир шарының бөтен хезмәтчел кешелек дөньясы траурда булды.

Ленин үлде, ләкин аның эше бөтен дөньядагы миллионнарча хезмәт ияләренең йөрәкләрендә яши. Ленин эше совет халкының җиңүләрендә, дөньяда эшче һәм крестьяннарның беренче социалистик дәүләтенең бөек казанышларында яши.

Кайгы белән үткән Ленин көннәрендә СССР Советларының II нче съездында иптәш Сталин Ильич васыятләрен үтәргә дип партия исеменнән бөек ант бирде.

Иптәш Сталин әйткән икән, аның бөтен халык исеменнән әйткәнлеген һәм иптәш Сталин әйткән икән, аның үтәләчәген һәр кем белде.

Ленин байрагы Ленин белән бергәләп бөтен гомере буена коммунизм өчен көрәшкән иптәш Сталинның ышанычлы кулларында.

Иптәш Сталин аерым алынган бер ил шартларында социализм төзергә мөмкинлеге турында Ленин таглиматын үстерде һәм өстәде, социалистик җәмгыят төзеп житкерү буенча бөтен планны теоретик һәм практик яктан эшләде.

Ленин эшен бөек дәвам иттерүче иптәш Сталинның даһи җитәкчелегендә безнең партиябез, совет халкы бу планны тормышка ашырды—социализм төзеде. Советлар иле Ленин юлы белән, иптәш Сталин җитәкчелегендә, коммунизмның тулысынча һәм тәмам җиңүенә бара.




Сулда—Ульяновский шәһәрендә В. И. Ленин туган йорт. Уңда—В. И. Ленин 1888 нче елда Казанда чагында торган йорт (Ленин урамында, хәзер бу йортта Ленин музее).

## ХАЛЫК ИЛЬИЧНЕ ИСКӘ АЛА

Украина башкаласы Киевнең интеллигенциясе Владимир Ильичнең тууына 70 ел тулу көненә эшлекле хәзерлек алып барды. Украина ССР Фәннәр Академиясенең фәнни-тикшеренү институтларында Ленин һәм ленинизм турында беседалар үткәрелә.

Хезмәт ияләренең бөек остазы Лениннең тууына 70 ел тулу көнендә—22 нче апрельдә Академиянең конференция залында бөтен Академия күләмендә зур кичә булачак.

⁂

Владимир Ильич Лениннең тууына 70 ел тулу көне Горькийда һәм Горький өлкәсендә киң рәвештә пропаганда эше алып бару белән билгеләнә.

Шәһәрнең иң зур предприятиеләрендә докладчылар һәм агитаторлар хәзерләү эше тәмам булды. 19 нчы апрельдә Орджоникидзе исемендәге заводта докладчылар өчен зур семинар үткәрелде. 20 нче апрельдә 90 нан артык докладчы һәм агитатор В. И. Лениннең тормышы һәм эше турында заводның цехларында беседалар үткәрделәр.

⁂

В. И. Лениннең тууына 70 ел тулу көненә Бакуда хәзерлек зур күтәренкелек белән барды. Пропагандистлар һәм агитаторлар Бөек Октябрь Социалистик революциясен оештыручы Лениннең тормышы һәм эше турында нефть промыслоларында һәм заводларда эшчеләргә һәм хезмәткәрләргә сөйлиләр.

⁂

Львов шәһәренең элекке сайлау участкыларындагы халык арасында эшләүче 120 агитатор В. И. Лениннең тормышы һәм эше турында Дәүләт университетында инструктив доклад тыңладылар. Алар сайлаучылар арасында һәм студентларның тулай торакларында шул ук темага беседалар үткәрәчәкләр.

## КАЗАН ЛЕНИН МУЗЕЙ-ЙОРТЫНДА

Безнең алда Ленин музей-йорты. Рәшәткәле кечкенә капкадан ишек алдына үтәбез. Сары буяуга буялган кыска гына ике катлы агач йорт эченә керәбез. Бу тарихи йортның ишегеннән атлау белән үк сез үзегезне үткән йөзнең 80 нче еллары обстановкасында күрәсез.

Уң як бүлмәдә портретлар һәм документлар галлереясе урнашкан. Монда кешелекнең бөек даһие Владимир Ильич Лениннең бала чагы һәм яшьлек еллары турындагы материаллар тупланган. Стенада Владимир Ильичнең атасы Илья Николаевич һәм анасы Мария Александровнаның портретлары. Шунда ук Ульяновлар семьясе төшкән рәсем һәм башкалар. Бу еллар патша Россиясендә полиция террорының һәм кара реакциянең котырынган еллары иде.

Патша хөкүмәтенең бу реакцион политикасына каршы Россиянең зур шәһәрләрендәге эшчеләр, университетларда укучы студентлар баш күтәрү һәм сходкалар оештырулар белән җавап бирделәр. Шушындый сходкаларның берсе 1887 нче елда Казан университетында да үткәрелә. Сходкада революцион настроениеле студентлар университет администрациясенә үзләренең политик таләпләрен куялар. Яңа гына университетка кергән Владимир Ильич та сходкада актив катнаша. 17 яшьлек студент Володяның сходкадагы беренче революцион чыгышы турында музейдә моңа кадәр булган документлар сөйли. Бу сходкада катнашкан Казан университеты элекке студенты Н. Н. Алексеевның язмалары тора. Бу истәлекте иптәш Н. Н. Алексеев түбәндәгечә яза:

„Университетның актовый залында җыелган студентлар башта бик озак дулкынландылар, шауладылар. Сходкаль алып бару өчен комитет (президиум) сайлаганнар. Сходкада тәртип урнашты...

Сходкада Владимир Ильич Ленин чыгып сөйләде. Ул патшалыкның изеп килүе турында, патша судының гаделсезлеге турында һәм барлык университетлардагы студентларның яшәп килә торган тәртипкә каршы протест белдерергә тиешлекләре турында сөйләде".

Сходканы оештыручы 40 студент кулга алына. Алар арасында Владимир Ильич тә була. Бу вакыйгадән соң Ленингә Казанда торырга рөхсәт ителми, полиция аны Казаннан ерак түгел, Кокушкино авылына сөргенгә җибәрә.

Кокушкино авылында торганда Владимир Ильичнең һәрбер адымын полиция күзәтеп тора. Монда, сөргендә вакытта, Владимир Ильич университетта үтелә торган барлык фәннәрне үзлегеннән өйрәнә һәм тирәнтен үзләштерә.

1888 нче елның көзендә Владимир Ильичкә Казанда торырга рөхсәт ителә. Ләкин аңа университетта укуын дәвам иттерергә рөхсәт бирелми. Сөргеннән кайткач Ленин музей урнашкан шушы йортта үзенең семьясе янында тора.

Без Владимир Ильич бүлмәсенә үтәбез. Беренче катта, кухня белән янәшә урнашкан бу бүлмә дә музейнең башка бүлмәләре кебек нак элекеге хәленә кайтарылган. Стеналарга үткән йөзнең 80 нче елларында кулланылган обойлар ябыштырылган. Бүлмәнең җиһазлары бик гади. Зәңгәр бизәкле одеял ябылган тимер кровать, өстәл, китап кую өчен асылмалы этажирка һәм бер урындык, бер читтә шахмат тактасы. Бүлмәнең барлык җиһазы менә шушы гына. Тәрәзә каршындагы өстәл өстендә Карл Маркс „Капитал"ның беренче томы ачылып куелган. Владимир Ильич шушы бүлмәдә кешелек акылының даһи әсәре булган „Капитал"ны өйрәнүне тирәнтен дәвам иттерә һәм Федосеевнең революцион түгәрәкләрендә катнаша. Бер үк вакытта Владимир Ильич үзлегеннән экстерн тәртибендә университетка имтихан бирергә дә хәзерләнә. Билгеле булганча, ул 1891 нче елны Петербург университетында экстерн тәртибендә имтихан тапшырып беренче дәрәҗәле диплом ала.

Музей-йортның икенче катында Ульяновлар семьясенең калган членнары торган. Икенче катта 4 бүлмә. Баскычтан күтәрелүгә аш бүлмәсе. Аннан Лениннең әнисе һәм кыз туганнары торган бүлмә. Анна Ильинична һәм аның янында Лениннең энесе Дмитрий Ильич бүлмәләре урнашкан. Бу бүлмәләрдә дә җиһазларның гадилеге, әйберләрнең тыйнаклыгы күзгә бәрелә. Бу йортта Ульяновлар семьясе 1889 нчы елның май аена кадәр тора һәм аннан соң Самарага күчә.

Казан музей-йортына һәр вакыт диярлек яңа документлар өстәлеп тора. Шушы көннәрдә генә Москвадагы Ленин музееннан Лениннең Симбирск гимназиясен тәмамлаган өчен бирелгән алтын медаль үрнәге, Петербург университетына экстерн тәртибендә имтихан тапшыруга рөхсәт бирелүне сорап язылган прошение һәм имтихан тапшырганнан соң аңа бирелгән диплом күчермәләре алынды. Шулай ук Ильичнең 4 яшьлек бала вакытта төшерелгән фото-рәсеменең күчермәсе, 1887 нче елның 4 нче декабрендә Казан университеты студентларының сходкасында катнашкан студентлар турындагы документлар алынды.

Казан музей-йортына хезмәт ияләре зур кызыксыну белән килә. Музейгә бер Татарстанның гына түгел, бәлки Советлар Союзының башка шәһәрләреннән дә экскурсиячеләр килә. Алар бөек Лениннең Казандагы тормышын зур кызыксыну белән өйрәнәләр һәм алар үзләренең тәэсирләрен язып калдыралар.

Кызыл Армия сугышчыларыннан бер группа болай дип язып калдырган:

— Без Кызыл Армия сугышчылары Казан Ленин музей-йортын зур канәгатьләнү белән карадык. Сөекле Лениннең бала вакты һәм Казанда үткәргән яшьлек еллары турындагы лекция безне бик нык дулкынландырды. Музейне оештырулары өчен партия һәм хөкүмәт житәкчеләренә чын күңелдән рәхмәт.

Укучы балалардан Евгений һәм Герман „Музейне караганнан соң без бөтен дөнья революциясе даһие Ильич укыган кебек укырга сүз бирәбез" дип язып калдырганнар.

Музейдә булган кешеләр бу йорттан тирән дулкынлану белән китәләр. Алар бөтен кешелек дөньясы горурлана торган бөек галим булган, бөтен дөнья хезмәт ияләренең даһи юлбашчысы һәм дусы булган кешенең—яшь Лениннең ягымлы образы турында үзләренең йөрәкләрендә тирән һәм онтылмаслык истәлек алып китәләр.

***Р. Нәҗметтинова.***
***З. Габитов.***

## НУРЛЫ КӨН

Бүгенге көн—
Язның матур көне
Нурлы булып керде тарихка;
Бүгенге көн
Даһи Ленинне
Бүләк итте бөек халыкка.
Халык бәхте өчен
Ленин туды.
Җир йөзенең шанлы бөркете
Ленин исеме
Тирәсенә халык
Монолиттай булып беректе.
Ленин—
Октябрьнең бөек юлбашчысы;
Ленин—
Давылларның бөек таңчысы;
Ленин—
Көрәшләрнең бөек баһадиры;
Ленин—
Азатлыкның бөек ачкычы.
Ленин белән
Гасырларның юлы
Бәхет кояшына борылды;
Ленин белән
Җирдә матур итеп
Социализм иле корылды.
Ленин белән
Беренче кат кеше
Гүзәллекне белде, таныды.
Ленин белән
Чын сөюне кеше
Мәхәббәтне сизде, татыды.
Ленин үлде...
Ләкин аның эшен
Кабатлыйлар җирдә миллионнар
Алар җиңә,
Алар башында
Ленин кебек бөек даһи бар.

*С. Каратай.*

## Язучыларның В. И. Ленингә багышланган кичәсе

Татарстан совет язучыларының Г. Тукай исемендәге кабинеты пролетариатның бөек юлбашчысы Владимир Ильич Лениннең тууына 70 ел тулуга багышлап 23 нче апрельдә зур әдәби кичә үткәрә. Кичәдә Владимир Ильич Лениннең тормыш юлы һәм революцион эше дигән темада Союзның җаваплы секретаре Муса Җәлил иптәш доклады куела. Кичәдә татар совет шагыйрьләреннән Хасан Туфан, Муса Җәлил, Әхмәт Исхак, Гадел Кутуй, Сибгат Хаким, Нәби Дәүли һәм башкалар үзләренең Ленингә багышлап язган яңа әсәрләрен укыячаклар. Кичәнең ахрында балалар иҗады олимпиадасында беренчелекне алган 51 нче мәктәп балаларының җыр һәм бию ансамбле чыгышы булачак.

## ЧИСТАЙ РАЙОНЫНДА

В. И. Лениннең тууына 70 ел тулу көненә карата ВКП(б) ның Чистай райкомы парткабинеты Лениннең тормышы һәм эше турындагы материаллардан күргәзмә һәм аның әсәрләреннән витрина оештырды. Докладчылар һәм агитаторлар өчен парткабинет янында һәр көнне консультация эшли. ВКП(б) райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге 36 кешене докладчы итеп билгеләде, алар В. И. Лениннең тууына 70 ел тулу көне турында докладлар ясаячаклар.

„Смена" колхозында В. И. Ленин турында 12 агитатор беседалар һәм кычкырып укулар үткәрәләр. Барлык мәктәпләрдә дә „Владимир Ильичнең балалык еллары" һәм „Ленин ничек укыды" дигән темаларда укучы балалар белән беседалар үткәрелә. (ТатТАСС).

## БЕЛДЕРҮ

23 нче апрель, кич 6 сәгатьтә Казан Дәүләт университетының актовый залында, „1 нче Май—халыкара пролетариат бәйрәме" дигән темада, докладчылар өчен, инструктив доклад үткәрелә. Докладчы—иптәш **Вайсенгольц.**

Редактор урынбасары **И. ҮЗБЕКОВ.**
Зам. редактора **И. УЗБЕКОВ.**

## ТЕАТР һӘМ КИНОЛАРДА:

**Татар Дәүләт Академия театрында**—23 нче апрельдә Н. Исәнбәт әсәре премьера **Хуҗа Насретдин.**

**Татар Дәүләт Опера театры**—ТДАТ бинасында бүген—Ирек.

**Зур театр**—премьера Метель.

**Дәүләт циркы**—бүген 3 бүлектә зур цирк уены һәм французча көрәш ярышы.

**Госфилармония** — 23 нче апрельдә Укытучылар йортында һәм 24 нче апрельдә Кызыл Армия йортында—бөек композитор **П. И. Чайковскийның** тууына 100 ел тулуга багышланган концертлар.

**Культура сарае** (Киров районы)—23 һәм 24 нче апрельдә Маскарад.

„Электро"—Аринка. „Унион"—Моряклар. „Кызыл Йолдыз"—Шатлык эзләгәндә. „Чаткы"—Ленин 1918 нче елда. „Пионер"—Инженер Кочинның ялгышуы. „Колхозник"—Выборг ягы. „Рот-Фронт"—Бөек таң. Культура сарае—Истребительләр.

Чит илләрдә

## СКАНДИНАВИЯДӘ СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

БЕРЛИН, 20 апрель. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе игълан иткән сводкада болай диелә:

„Нарвик, Тронгейм, Берген, Ставангер һәм Кристиансунд тирәләрендә Германия гаскәрләре алган урыннарда бернинди әһәмиятле вакыйга булмады. Берген районында Германия гаскәрләре күп кенә атауларны алдылар. Кристиансунд районында, Хегеланд якынында норвегиялеләрнең яңа частьләре коралсызландырылдылар. Пленгә алынучыларның һәм кулга төшерелгән сугыш кирәк-яракларының саны артканнан артып тора. 18 нче апрельдә булган исәпләүләр немецләрнең кулга төшерелгән сугыш кирәк-яраклары 180 орудиедән һәм 300 пулеметтан гыйбарәт булганлыкны күрсәтә.

Норвегиянең көнбатыш яры буенда Германия самолетлары дошманның сугыш корабларына һәм транспортларына атака ясадылар. Бомбалар дошманның бер крейсерына һәм ике транспортына тиде".

БЕРЛИН, 20 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросы, англичаннар Норвегиянең берничә пунктында гаскәрләр төшерделәр һәм Норвегия властьлары белән элемтә урнаштырдылар дигән хәбәрләрне анлатып, түбәндәгечә белдерә: „Бу унай белән Германия тарафыннан Төньяк Норвегиянең берничә пунктында англичаннар кечерәк кенә десантлар төшерделәр һәм алар немецләрнең даими контроле астында торалар дип белдерәләр. Англичаннарның бу отрядлары белән Германия гаскәрләре арасында җидди кораллы бәрелешләр булуга исәп тоту мөмкинме икән. Норвегиялеләр командованиесе белән „элемтә" дигән нәрсә Норвегия командованиесенең һәм халкының немецләргә мәгънәсез каршылык күрсәтүне дәвам иттерүләреннән гыйбарәт. Германия Норвегиядә һәр төрле сугыш хәрәкәтләрен туктату алдында тора. Солых урнаштыруга тоткарлык итәчәк көчләр алып ташланачаклар яки тар-мар ителәчәкләр. Норвегиянең таркау гаскәри частьләре өчен Англия гаскәрләре һичбер төрле реаль ярдәм булып тормыйлар".

БЕРЛИН, 19 апрель. (ТАСС). Германиянең авторитетлы даирәләрендә ике-өч атна эчендә Норвегиядә сугыш операцияләре тәмам булыр дип санныйлар.

ЛОНДОН, 20 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, кичә иртә белән Эльверум районында сугышлар башланган. Монда Норвегия гаскәрләре үз позицияләрен кулларында тоталар. Германия гаскәрләре кечерәк кенә отрядлар булып хәрәкәт итәләр. Нарвик районында немецләрнең хәле җидди. Нарвик якынында, Ромбаксегада һәм Швеция чигеннән 5 километр ераклыкта тупланган Германия гаскәрләре асылда үз базаларыннан аерылганнар.

НЬЮ-ЙОРК, 19 апрель. (ТАСС). Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англия авиациясе Ставангерны бомбага тоткан. Күп кенә йортлар җимерелгән, яралаучылар күп.

НЬЮ-ЙОРК, 20 апрель. (ТАСС). Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, кичә Нарвикка тәэмин итү әйберләре китергән күп санлы Германия самолетлары немецләрнең Нарвикта англичаннарга каршы сугыш башларга теләүләрен күрсәтә.

Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, немецләр Ослодан һәм Конгсвингердан төньякка таба 35 мильгә алга киткәннәр. Норвегиялеләр Гломма елгасының ике ягындагы шәһәрләрдән дә кучканнәр.

ЛОНДОН, 20 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англия гаскәрләре Лофотен атауларын тулысынча алганнар. Эльверум һәм Хамар районында ике көн буена каты сугышлар бара. Ләкин аннан хәбәрләр бөтенләй диярлек юк.

Кичә Стокһольмдә Швециянең көнбатыш ярындагы Скагеррак проливында орудиедән атышу ишетелү турында күп санлы хәбәрләр алынды. Хәбәр итүләренә караганда, бу ату тавышы күп урыннарда ишетелгән.

Рейтер агентлыгының хәрби күзәтүчесе, Эльверум—төньяк Норвегия белән элемтә тоту өчен әһәмиятле пункт дип яза. Конгсвингер алынганнан соң Германия гаскәрләренең алга баруына Норвегия отрядлары төрлечә комачаулык итәләр. Норвегиялеләр күперләрне шартлаталар һәм юлларга миналар куялар. Әгәр Ромсдалс-фиордка керү юлына Канада гаскәрләре төшерелү турындагы хәбәрләр расланса, якын арада Хамар секторында каты сугышлар күтәрелергә кирәк.

НЬЮ-ЙОРК, 20 апрель. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Швеция матбугаты Намсуста, Льерданда һәм Молдеда французларның бер һәм англичаннарның ике дивизиясе төшерелүне хәбәр итә. Немецләрнең Хамарны һәм Эльверумны кулларында тотуларын хәбәр итәләр.

ЛОНДОН, 20 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англиянең сугыш корабларын озатып баручы самолетлар Ставангерны бомбага тотканда вакытта бер „Гейнкель"не, „Дорнье" типындагы бер оча торган көймәне бәреп төшергәннәр һәм дошманның өч самолетына зыян китергәннәр. Болардан тыш, Англия самолетлары ташлаган ике бомба Германия эсминецларына тигән. Англия авиациясе Нарвик янында да дошман самолетларына атака ясап, аларның бер өлешен юк иткән.

## КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

**КӨНЬЯК КЫТАЙДА.** Соңгы көннәрдә сугышлар Кантоннан көньяк-көнбатыштарак булды. 14 нче апрельдә Кантоннан көньяктарак кытайлар Цзянмыньгә үтеп керделәр. Урамда булган сугышта японнар 200 ләп кешеләрен югалттылар. Кантоннан көнчыгыштарак 17 нче апрельдә япон гаскәрләре Линлунью шәһәренә атака ясарга маташтылар. Атака кире кагылды.

**ТӨНЬЯК КЫТАЙДА.** Шаньси провинциясенең көньяк өлешендә японнар Хундун белән Туньлю арасындагы районда һөҗүм ясарга маташтылар. Һөҗүм кире кагылды. Шул ук районда японнарның 7—8 мең кешелек гаскәре бомбардировка авиациясе ярдәме белән кытай гаскәрләренең Чжунтяошань тауларындагы базаларына һөҗүм башладылар. Сугышлар берничә пунктта башланды.

Күптән түгел генә японнар Шаньси провинциясенең көньяк-көнбатыш өлешендә һөҗүм ясарга маташтылар. Бу һөҗүм барлык юнәлешләрдә кире кагылды.

20 апрель. (ТАСС).

## ҮЗӘК МУЗЕЙДӘ

Москвада В. И. Ленин үзәк музее Советлар Союзы хезмәт ияләре арасында гаять зур популярлек белән файдалана. Аның киң һәм якты заллары һәр көнне меңнәрчә москвалылар һәм илебезнең төрле шәһәрләреннән килгән экскурсантлар белән тулы була. Музей ачылган көннән—1936 нчы елның 15 нче маеннан башлап, анда 4,5 миллионнан артык кеше булды. Хәзер Владимир Ильич Лениннең тууына 70 ел тулу көне якынлашу уңае белән музейне карарга килүчеләрнең агылуы тагын да арта. Предприятиеләрдән һәм учреждениеләрдән экскурсияләргә күп санда заявкалар керә. Соңгы бишкөнлек эчендә музейдә 15 меңнән артык кеше булды.

Музейне карарга килүчеләр В. И. Лениннең һәм аның бөек көрәштәше иптәш Сталинның тормышларын һәм революцион эшләрен чагылдыручы экспонатлар белән нык кызыксынып танышалар. Музей турындагы фикерләрне язу кенәгәсе шатлыклы язмалар белән тулы. Музейне карарга килүчеләр большевизмның гүзәл хәзинәсе һәм мәктәбе булган бу музейне төзегән өчен партиягә һәм хөкүмәткә кайнар рәхмәт белдерәләр.

Музейдә булган укытучы иптәш Шенкман кенәгәгә түбәндәге сүзләрне язып калдырган:

— Музей Лениннең тормышын, эшен тулы һәм күп яклы итеп чагылдыруы белән зур тәэсир калдыра. Музейне оештыручыларга чын күңелдән рәхмәт хисе белән китәсең.

Музейгә өзлексез рәвештә яңа материаллар өстәлә. Владимир Ильичнең тууына 70 ел тулу көненә күп кенә экспонатлар куела. Музейнең экспозициясе „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"ннан өземтәләр белән, В. И. Лениннең һәм И. В. Сталинның гаять әһәмиятле әсәрләренең эчтәлеген тирәнтен ача торган материаллар белән шактый тулыландырыла.

В. И. Лениннең тууына 70 ел тулу көне уңае белән музей фәнни работникларыннан һәм иң яхшы экскурсия житәкчеләреннән 30 докладчы билгеләде. Алар Владимир Ильичнең тормышы һәм революцион эше турында предприятиеләрдә һәм учреждениеләрдә докладлар ясаячаклар. (ТАСС).

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 1396. ТИПОГРАФИЯ «ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 1540.